КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 декабрь г.Казань № 1241

«2020 елга Татарстан Республикасында гражданнарны торак белән тәэмин итүдә дәүләт ярдәме күрсәтү» программасы турында

Татарстан Республикасында гражданнарны һәркем сатып алырлык торак белән тәэмин итү, гамәлгә ашырыла торган кайбер дәүләт программалары чаралары кысаларында «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем сатып алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасын тормышка ашыру чараларын финанслашуны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «2020 елга Татарстан Республикасында гражданнарны торак белән тәэмин итүдә дәүләт ярдәме күрсәтү» программасын расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалкан дип санарга:

«2019 елга Татарстан Республикасында гражданнарны торак белән тәэмин итүдә дәүләт ярдәме күрсәтү» программасы турында» 2019 ел, 15 февраль, 104 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга Татарстан Республикасында гражданнарны торак белән тәэмин итүдә дәүләт ярдәме күрсәтү» программасы турында» 2019 ел, 15 февраль, 104 нче карары белән расланган «2019 елга Татарстан Республикасында гражданнарны торак белән тәэмин итүдә дәүләт ярдәме күрсәтү» программасына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 13 сентябрь, 827 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга Татарстан Республикасында гражданнарны торак белән тәэмин итүдә дәүләт ярдәме күрсәтү» программасы турында» 2019 ел, 15 февраль, 104 нче карары белән расланган «2019 елга Татарстан Республикасында гражданнарны торак белән тәэмин итүдә дәүләт ярдәме күрсәтү» программасына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 28 декабрь, 1226 нчы.

3. Бу карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 30 декабрь, 1241 нче
карары белән расланды

**«2020 елга Татарстан Республикасында
гражданнарны торак белән тәэмин итүдә дәүләт ярдәме күрсәтү»
программасы**

**Программа паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2020 елга Татарстан Республикасында гражданнарны торак белән тәэмин итүдә дәүләт ярдәме күрсәтү (алга таба – Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы |
| Программаны яраштыручы | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы |
| Программаны төп эшләүчеләр | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы |
| Программаның максаты | Гражданнарның торакка конституцион хокукын тормышка ашыру өчен уңай шартлар тудыру |
| Программаның бурычлары | Татарстан Республикасында керемнәре төрле дәрәҗәдә булган гражданнарны сатып алырлык бәядәге торак белән тәэмин итүнең нәтиҗәле системасын оештыру, гражданнар өчен торакның сатып алырлык булуын тәэмин итә торган финанс механизмнарын үстерү, шулай ук Татарстан Республикасында милек хокукы яки наем нигезендә даими һәм вакытлыча яшәү өчен торакның нәтиҗәле базарын формалаштыру |
| Программаны тормышка ашыру вакыты | 2020 ел |
| Программаны үтәүче | «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциягә карамаган оешмасы – махсуслаштырылган оешма (Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2005 елның 23 июнендәге ПУ-265 номерлы Указы) |

| | |
|---|---|
| Программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр һәм аның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 1. «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасында гражданнарны торак белән тәэмин итү максатларында Программа чараларын кимендә 16 750,964 млн.сум күләмендә финанслау.<br>2. «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә торакка хокукны социаль ипотека системасында тормышка ашыручы гаиләгә һәр бала туганда, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда сатып алына торган торак өчен беренче һәм агымдагы кертемнәрне түләү рәвешендә дәүләт ярдәмен гаиләләрне махсуслаштырылган оешманың җыелма реестрына керткән вакыттан 200,0 мең сум күләмендә, әмма Программаны финанслауның күздә тотылган күләмнәре нигезендә бала туган вакытка торак урынның түләнмәгән өлеше кыйммәтеннән яки махсуслаштырылган оешма белән төзелгән максатчан акча заемы шартнамәсе буенча төп бурычның түләнми калган суммасы һәм процентларыннан арттырмаган 700,0 млн.сум күләмендә күрсәтү.<br>3. Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына кертелергә тиешле җир кишәрлекләрен формалаштыру һәм махсуслаштырылган оешмага җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү.<br>Татарстан Республикасы территориясендә Программаны үтәүче тарафыннан төзелгән торак күләме барысы бергә 205,3 мең кв.метр тәшкил итәргә тиеш. 1 кв.метр торакның инвестицияләгән чыгымнарының уртача кыйммәте 36,6 мең сумнан артмаска тиеш. Социаль ипотека системасында реализацияләнә торган 1 кв.метр торакның башлангыч кыйммәте махсуслаштырылган оешма тарафыннан төзелешне финанслаганда, җир кишәрлеген капиталлаштырганда гамәлгә ашырыла торган чыгымнар, күчемсез мөлкәт базары торышы исәпкә алынып билгеләнә |
| Программаны финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыруны тәэмин итү чараларын финанслауга җибәрелә торган чыгымнарның гомуми күләме 16 750,964 млн.сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>10 366,4 млн.сум – Программаны яраштыручы һәм үтәүче арасында төзелгән килешү нигезендә үткән елда |

| | |
|---|---|
| | акча күчерүләрне исәпкә алып, Программа чараларын үтәүгә, шул исәптән 6,319 млн.сум – Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына кертелергә тиешле җир кишәрлекләрен формалаштыруны финанслауга Татарстан Республикасы оешмалары түләүләре хисабына;<br>700,0 млн.сум – балалары туган яки уллыкка (кызлыкка) алган гаиләләргә сатып алына торган торак өчен беренче һәм агымдагы кертемнәрне түләү рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү акчасы хисабына;<br>5 684,564 млн.сум – Программаны үтәүче акчасы хисабына |
| Программаның үтәлешен тикшерүдә тотуны оештыру системасы | Программаның үтәлешен тикшерүдә тоту һәм яраштыру Программаны яраштыручы тарафыннан тәэмин ителә |

## I. Проблеманың тасвирламасы

«Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, 2005 елдан башлап, торак төзелешен үстерү гамәлгә ашырыла.

Программаның төп юнәлеше – социаль ипотека системасында Татарстан Республикасы халкына, шулай ук торак урыннар сатып алырга теләгән билгеләнгән гражданнарның аерым категорияләренә, шул исәптән кулланучылар кооперативлары әгъзаларына махсуслаштырылган оешма, гражданнарга һәм юридик затларга ипотека кредиты бирү аша торак реализацияләү. Программа кысаларында торак төзелешен үстерү һәм республика халкын һәркем сатып алырлык торак белән тәэмин итү максатларында торак йортлар төзүне финанслашуга һәм төзүгә акча җәлеп ителә.

Аерым гражданнарның керемнәре түбән булганда һәм аларның финанс институтлары тотрыклылыгына ышанычы булмаганда, Программаны тормышка ашыру халыкның торак шартларын яхшырту өчен җыелган акчасын кыска вакыт эчендә икътисадның реаль секторына җәлеп итәргә мөмкинлек бирә. Торак урыннарны махсуслаштырылган оешмадан сатып алырга теләгән билгеләнгән гражданнар, акчасын туплап һәм киң масштаблы төзелешкә кертә барып, торак проблемасын хәл итүнең уникаль ысулына ия була. Программа дәүләт хакимияте органнарының үзара тыгыз хезмәттәшлегендә гамәлгә ашырыла.

## II. Программаның төп максатлары, бурычлары һәм аны тормышка ашыру вакытлары

Программаның максаты – торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарның торакка конституцион хокукын тормышка ашыру өчен уңай шартлар тудыру.

Программаның бурычлары – Татарстан Республикасында керемнәре төрле дәрәҗәдә булган гражданнарны сатып алырлык бәядәге торак белән тәэмин итүнең нәтиҗәле системасын оештыру, гражданнар өчен торакның сатып алырлык булуын тәэмин итә торган финанс механизмнарын үстерү, шулай ук Татарстан Республикасында милек хокукы яки наем нигезендә даими һәм вакытлыча яшәү өчен торакның нәтиҗәле базарын формалаштыру.

Программаны тормышка ашыру вакыты – 2020 ел.

## III. Программа чаралары

1. Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында, шулай ук махсуслаштырылган оешма аша торак урыннар сатып алырга теләген белдергән һәм махсуслаштырылган оешманың җыелма реестрына кертелгән гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итү максатларында Программа чараларын финанслау.

2. «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә торакка хокукны тормышка ашыручы гаиләгә һәр бала туганда, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда сатып алына торган торак өчен беренче һәм агымдагы кертемнәрне түләү рәвешендә дәүләт ярдәмен гаиләне махсуслаштырылган оешманың җыелма реестрына керткән вакыттан 200,0 мең сум күләмендә, әмма бала туган вакытка торак урынның түләнмәгән өлеше кыйммәтеннән яки махсуслаштырылагн оешма белән төзелгән максатчан акча заемы шартнамәсе буенча төп бурычның түләнми калган суммасыннан һәм процентларыннан артмаган күләмдә күрсәтү.

3. Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына кертелергә тиешле җир кишәрлекләрен формалаштыру һәм махсуслаштырылган оешмага җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү.

## IV. Программаның ресурслар белән тәэмин ителеше

Программаны тормышка ашыру чараларын финанслауга җибәрелә торган чыгымнарның гомуми күләме 16 750,964 млн.сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

10 366,4 млн.сум – Программаны яраштыручы һәм үтәүче арасында төзелгән килешү нигезендә үткән елда акча күчерүләрне исәпкә алып, Программа чараларын үтәүгә, шул исәптән 6,319 млн.сум – Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына кертелергә тиешле җир кишәрлекләрен формалаштыруны финанслауга Татарстан Республикасы оешмалары түләүләре хисабына;

700,0 млн.сум – балалары туган яки уллыкка (кызлыкка) алган гаиләләргә сатып алына торган торак өчен беренче һәм агымдагы кертемнәрне түләү рәвешендә дәүләт ярдәме күрсәтү акчасы хисабына;

5 684,564 млн.сум – Программаны үтәүче акчасы хисабына.

## V. Программаны тормышка ашыру механизмы

Программаны яраштыручы Программаны үтәүче белән аны тормышка ашыру турында килешү төзи.

Программаны үтәүче төзелгән килешү нигезендә аны тулы күләмдә тормышка ашыруны оештыра һәм Программаны тормышка ашыру турындагы хисапларны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына килешү белән билгеләнгән вакытларда һәм формада тапшыра.

Программаны тормышка ашыруның барышын тикшерүдә тоту аның яраштыручысы – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан тәэмин ителә.

## VI. Программаның икътисадый һәм социаль нәтиҗәлелеген бәяләү

1. Программа түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:

Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында, шулай ук махсуслаштырылган оешма аша торак урыннар сатып алырга теләген белдергән һәм махсуслаштырылган оешманың җыелма реестрына кертелгән гражданнарның аерым категорияләрен торак белән тәэмин итү чараларын кимендә 16 750,964 млн.сум күләмендә финансларга, 205,3 мең кв.метр торакны эксплуатацияләүгә кертергә;

«Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә торакка хокукны тормышка ашыручы гаиләгә һәр бала туганда, шулай ук һәр баланы уллыкка (кызлыкка) алганда сатып алына торган торак өчен беренче һәм агымдагы кертемнәрне түләү рәвешендә дәүләт ярдәмен гаиләне махсуслаштырылган оешманың җыелма реестрына керткән вакыттан 200,0 мең сум күләмендә, әмма бала туган вакытка торак урынның түләнмәгән өлеше кыйммәтеннән яки махсуслаштырылагн оешма белән төзелгән максатчан акча заемы шартнамәсе буенча төп бурычның түләнми калган суммасыннан һәм процентларыннан артмаган күләмдә күрсәтергә;

Татарстан Республикасы җирләренең дәүләт резервына кертелергә тиешле җир кишәрлекләрен формалаштырырга һәм махсуслаштырылган оешмага җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирергә.

2. Татарстан Республикасы территориясендә төзелгән торак күләме 205,3 мең кв.метр тәшкил итәргә тиеш.